ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 377 от 27.08.2024г.

***Постановление*** ***Карар***

Түләүле хезмәтләргә бәяләрне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәткән (эшләр башкарган) өчен гражданнар һәм юридик затлар өчен түләү билгеләү тәртибен раслау турында» 2011 елның 05 апрелендәге 361 номерлы карарын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «С. Гобәйдуллина исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы күрсәтә торган түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Түләүле хезмәтләргә бәяләрне раслау турында» 2021 елның 25 августындагы 487 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча беренче урынбасары Е.В. Никитинга йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов